# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге составына керүче Сахар авылы

11 ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахар авыл җирлеге составына керүче Сахар торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Сахар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту;

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту;
- Суходол инеше аша җәяүлеләр күперенә таба сазлыклы урын буенча юлны төзекләндерү;

- Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга обелиск сатып алу һәм урнаштыру;

3. Әлеге карарны Сахар авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга. (как в назначении каждому населенному пункту)

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сахар авыл җирлеге башлыгы Л.В.Шаброва